СОВЕТ
АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

21.01.2026 г. Агрыз № 6-4

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының 2013 елның 15 ноябрендә 28-2нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турындагы Федераль законга үзгәрешләр кертү турындагы 2023 елның 2февралендә кабул ителгән 517-ФЗ номерлы Федераль законга, Россия Федерациясе эчке эшләр органнары хезмәткәрләре өчен социаль гарантияләр турындагы Федераль законның 9нчы маддәсенә һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турындагы 2020 елның 20 июлендә кабул ителгән 241-ФЗ номерлы Федераль законга, шулай ук Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турындагы Федераль закон нигезендә, норматив хокукый актны гамәлдәге законнарга туры китерү максатыннан, Татарстан Республикасының Әгерҗе муниципаль районы Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының 2013 елның 15 ноябрендә кабул ителгән 28-2нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты турында нигезләмәгә (алга таба - нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 4нче бүлегенең 15нче абзацындагы текстны:

«- муниципаль хокукый актларны бастырып чыгару, җирле әһәмияте булган мәсьәләләр буенча муниципаль хокукый актларның проектларын тикшерү, муниципаль берәмлек халкына муниципаль берәмлекнең социаль-икътисади һәм мәдәни үсеше, аның иҗтимагый инфраструктурасының үсеше турында һәм башка рәсми мәгълүматлар җиткерү өчен басма массакүләм чарасы булдыру» түбәндә бирелгән эчтәлектәге текст белән алыштырырга:

“ - муниципаль хокукый актларны халыкка җиткерү, муниципаль берәмлек халкына рәсми мәгълүматны җиткерү өчен басма массакүләм мәгълүмат чарасы һәм (яки) челтәрле басма булдыру” ;

“ - участок вәкаләтле полиция хезмәткәре вазифасын башкаручы хезмәткәргә һәм аның гаилә әгъзаларына хезмәткәрнең күрсәтелгән вазифаны башкару чорына торак бина бирү”;

2. Бу карарны Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында (https://agryz.tatarstan.ru) Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга, шулай ук Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) интернет челтәрендә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының Законлылык, регламент һәм депутат этикасы буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет рәисе
Муниципаль район Башлыгы Л. Ф. Нургаянов